**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423959, Республика Татарстан,
Ютазинский район, деревня Малые Уруссу,
улица Советская, дом 18а.
тел. 85593 4-23-10, факс 85593 4-23-40

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423959, Татарстан Республикасы,
Ютазы Районы, Кече Урыссу авылы,
Совет урамы, 18а йорты.
эл.адрес Tash.Utz@ tatar.ru

---

№ 14 28 май 2018ел

КАРАР

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
"Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләрне
рәсмиләштерү һәм урнаштыру турында Нигезләмәне раслау турында

2018 елның 11 гыйнварындагы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В. Г. Шәйхразиев җитәкчелегендә узган Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында ВШ-12-7 номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмә беркетмәсен үтәү максатында, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында»гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 29.03.2012 елгы карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны регламентлаштыра торган теркәлгән Нигезләмәне расларга.
2. Төзекләндерү эшләрендә катнашучы физик һәм юридик затларга, урам исемнәре һәм йортлар номерлары белән күрсәткечләр рәсмиләштергәндә һәм урнаштырганда, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә урам исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны регламентлаучы Нигезләмәгә таянып эш итәргә.
3. Муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләргә урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләрне әлеге карарга туры китереп үзгәртергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм (http:pravo.tatarstan.ru).Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге Башлыгы: Р.К. Валеев.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карары белән расланды
2018 елның 28 маеннан №14

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләрен рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны регламентлаучы Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең барлык күчемсез милек объектларында , шулай ук барлык урамнарында урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләре рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны регламентлый.

1.2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Ташкичү авыл җиирлеге" муниципаль берәмлегенең барлык урамнарында урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләрне Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә (рус, татар телләрендә) язарга (Кушымта №1).

1.3. Биналарның фасадларында тыела:
- урам исемнәре һәм йортлар номерлары белән күрсәткечләрне үзбелдеклек белән рәсмиләштерү һәм урнаштыру;
- башка күрсәткечләрне рәсмиләштерү һәм урнаштыру;
- расланмаган үрнәктәге урам исемнәре һәм йортлар номерлары белән күрсәткечләр урнаштыру;
- урам исемнәре һәм йортлар номерлары күрсәткечләре белән янәшә элмә такталар, консольләр, шулай ук аларны күрүне кыенлаштыра торган объектларны урнаштыру;
- урам исемнәре һәм йортлар номерлары белән күрсәткечләрне фасадның чыгынкы элементлары янында яки фасадның эчкә кергән участокларында, кәрниздә, капкаларда урнаштыру;
- урам исемнәре һәм билгеләнгән урын номерлары белән күрсәткечләрне үзбелдеклек белән күчерү.

1.4. Урам исемнәре һәм йортлар номерлары булган яктылык күрсәткечләрен кабызу һәм сүндерү урамнарны яктыртылыш эше режимында башкарыла.

1.5. Биналар чиста һәм төзек урам исемнәре һәм йортларның номерлары язылган күрсәткечләр белән җиһазландырылырга тиеш.

1.6. Россия Федерациясе закончалыгы, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләре белән расланган Кагыйдәләр (алга таба - Төзекләндерү кагыйдәләре) нигезендә, урам исемнәре һәм йортларның номерлары күрсәтелгән күрсәткечләрнең пычранган булуы, төзексезлеге һәм бөтенләй булмавы , билгеләнгән үрнәктә булмавы, биналар нумерациясе тәртибе өчен биналарның милекчеләре, хуҗалары һәм кулланучылары булган юридик һәм физик затлар җаваплы .

III. Урамнар һәм йортлар номерлары белән күрсәткечләр урнаштыру тәртибе

2.1. Ике телдәге урам исеме һәм йорт номеры белән җирлекнең барлык урамнарында урнаштырылучы күрсәткечнең зурлыгы һәм формасы 1 нче Кушымтада тәкъдим ителгән:
- күрсәткеч полимер япмалы 0,8 мм калынлыгындагы штампланган табаклы (листовой) металлдан әзерләнә;
- күрсәткечнең төсе: шрифтлары - зәңгәр, яшел төстә, фоны - ак төстә;
- аншлагның номеры белән берләштерелгән габарит зурлыгы: 800 х 200 мм һәм 500 х 150 мм;
- номер билгесенең габарит зурлыгы: 250 х 200 мм һәм 150 х 150 мм.

III. Урам исемнәре һәм йортлар номерлары белән күрсәткечләр урнаштыру тәртибе

3.1. Урам исемнәре һәм йортлар номерлары белән күрсәткечләр бина фасадларында түбәндәге таләпләргә туры китереп урнаштырыла:
- урам исемнәре һәм йортлар номерлары булган күрсәткечләр җәяүлеләр һәм транспорт хәрәкәте шартларын, биналарның күзаллану дистанциясе, архитектурасы, яктыртылышы, яшел утыртмалар кабул ителүе дистанцияләрен исәпкә алып урнаштырыла;
- урам исемнәре язылган күрсәткечләр урам чатларында урнашкан биналар стеналарында бинаның ике ягында да урнаштырыла;
- күрсәткечне ике стена арасындагы вертикаль күчәргә, фасадның архитектур өлешләренә һәм күрше фасадлардагы күрсәткечләр урнаштыруның бердәм вертикаль билгесенә беркетергә, күрсәткечләрне фасад участогында урнаштыру, чыгынкы архитектур детальләрдән азат булган, тышкы каплап торучы объектлар (агачлар, корылмалар) булмаган урында урнаштырырга кирәк;
- урамнар чатларында күрсәткечләр әлеге чатларга чыгучы йортларда билгеләнә;
- урам исемнәре һәм йортлар номерлары белән күрсәткечләр төп фасадта - фасадның уң ягыннан - ара стенага; транспортның бер яклы хәрәкәте булган урамнарда - транспорт хәрәкәте юнәлешенә якын якта; арка яки төп керү юлы янында - уң яктан яки уем өстендә (над проемом)

урнаштырылырга тиеш; ишегалды фасадларында - квартал эчендәге юл ягыннан ара стенада; сәнәгать предприятиеләренең ихаталарында һәм корпусларында – төп керүюлы яныннан – уң якта.

3.2. Урам исемнәрен рус һәм татар телләрендә язу аларның авыл җирлеге урамнары Реестрында ничек аталуына туры китереп башкарыла.

Рус һәм татар телләрендә исемнәр тулы булырга тиеш. Проспект, урам, тыкырык (переулок, проезд) сүзләре рус телендә кыскартылган вариантта кулланыла ала. Татар телендә кыскартылган вариантта - ур. дип һәм тулы вариантта - тыкырыгы, урамы дип кулланыла.

Урам исеме баш хәрефләрдән, урам, тыкырык, тыкырык (проезд) сүзләре – юл хәрефләре белән языла.

3.3. Яраксызга чыккан һәм зыян күргән урам исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр ремонтланырга яки алыштырылырга тиеш.

3.4. Йортларның номерларын урнаштыру бина милекчеләренең акчалары хисабына башкарыла.

Кушымта №1
Муниципаль берәмлектә урам исемнәре
һәм йорт номерлары белән күрсәткечләрне
рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны регламентлаучы
Нигезләмәгә

| МАТЕРИАЛ | ТӨСЕ |
|---|---|
| 0,8 мм калынлыктагы табаклы (листовой) металлдан штамповка, буяу техникасы - полимер | Фоны - ак, хәрефләре зәңгәр, яшел |